**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.06.2021 Балык Бистәсе штп. № 123пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Социаль файдаланудагы торак фондының торак биналарын наем шартнамәләре буенча торак биналары алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2019 елның 25 гыйнварындагы 08пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2021 елның 21 гыйнварындагы 05-51/316 номерлы хатын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2016 елның 21 июнендәге 96пи номерлы карарына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 25 гыйнварындагы 08пи номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 185пи, 2019 елның 09 июлендәге 214пи номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1.4 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитет җитәкчесенең 2020 елның 24 апрелендәге 19ри номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән (алга таба-Кагыйдәләр)»;

1.2.) 2.5 пунктның 3 пунктчасы, 2.6 пунктның 1 пунктчасы үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д.Н. Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов